КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 декабрь

г.Казань

№ 1320

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 7 июнь, 538 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 7 июнь, 538 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="2">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 322 675,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итүгә планлаштырыла торган федераль бюджет акчалары исәбеннән 317 400,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 0,0 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар - 5 275,6 мең сум.</td></tr>
<tr><td>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барысы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклар дан акча</th></tr>
<tr><td>2022</td><td>267 475,6</td><td>0,0</td><td>262 200,0</td><td>5 275,6</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>55 200,0</td><td>0,0</td><td>55 200,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>322 675,6</td><td>0,0</td><td>317 400,0</td><td>5 275,6</td></tr>
</table>
Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммасы ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә төгәлләштереләчәк.<br>Программаны гамәлгә ашыруның федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин ителеше күләме Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк;</td></tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Еллар буенча бүлеп, Программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет | 2024 елга Татарстан Республикасы территориясендә электр автомобиль транспорты өчен кимендә 194 кору инфраструктурасы объектларын эксплуатацияләүне тәэмин итү (2021 ел дәрәҗәсенә карата электр автомобиль транспорты өчен кору инфраструктурасын ким дигәндә 138 объектка арттыру)»; |

| | |
|---|---|
| нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |

Программаның I бүлегендәге «Татарстан Республикасында электротранспорт чаралары һәм  кору инфраструктурасын үстерү» бүлекчәсенең дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

Программаның II бүлегендә:

уналтынчы абзацта «2022 елда Татарстан Республикасында электр транспорты өчен кору инфраструктурасының 95 объектын урнаштыру планлаштырыла» сүзләрен «Татарстан Республикасында 2022 - 2023 еллар чорында кору инфраструктурасының 115 объектын, шул исәптән  2022 елда - 95 берәмлекне һәм 2023 елда - 20 берәмлекне урнаштыру планлаштырыла» сүзләренә алмаштырырга;

9 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 нчы таблица

Татарстан Республикасы территориясендә 2022 – 2024 еллар чорына электр транспорты чаралары өчен кору инфраструктурасы объектларын урнаштыруга планлаштырылучы объектлар саны турында мәгълүмат

| Кору инфраструктурасы объектларын урнаштыруны күздә тоткан оешма исеме | Финанслау күләме, мең сум | Кору инфраструктурасы объектлары саны, берәмлек | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | барысы |
| В.Д.Шашин ис. «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте | 5 275,6 | 3 | - | - | 3 |
| «Транснефтепродукт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | * | 1 | - | - | 1 |
| «Таиф-НК» акционерлык җәмгыяте | * | 1 | - | - | 1 |
| «РеСтарт» коммерцияле булмаган автоном оешмасы | * | 1 | - | - | 1 |
| «Санкт-Петербург ЮИТ» акционерлык җәмгыяте, «Талони» торак комплексы | * | - | 1 | - | 1 |
| Җирле үзидарә органнары | * | 2 | - | - | 2 |
| Автомобиль газ тутыру компрессор станцияләрен төзү операторлары | * | 7 | 7 | - | 14 |
| Кору станцияләрен төзү операторлары | 317 400,0** | 95 | 20 | - | 115 |
| Барысы | 322 675,6 | 110 | 28 | - | 138 |

*Финанслау күләме һәм чыганаклары тиешле шартнамәләр һәм килешүләр төзү факты буенча ачыкланачак.

** Җиһаз сатып алуга һәм кору инфраструктурасы объектларын технологик тоташтыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансферт күләме ел саен Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе нигезендә раслана.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 322 675,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

федераль бюджет чаралары - 317 400,0 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 0,0 мең сум;

бюджеттан тыш чыганаклардан - 5 275,6 мең сум;

(мең сум)

| Ел | Барысы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклардан акча |
|---|---|---|---|---|
| 2022 | 267 475,6 | 0,0 | 262 200,0 | 5 275,6 |
| 2023 | 55 200,0 | 0,0 | 55 200,0 | 0,0 |
| 2024 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Барлыгы | 322 675,6 | 0,0 | 317 400,0 | 5 275,6 |

Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммасы ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә төгәлләштереләчәк.

Программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

Электр транспорты чаралары өчен кору инфраструктурасы объектларын урнаштыру чараларының бюджеттан тыш чыганаклары исәбенә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән тиешле оешмалар арасында ниятләр турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырылачак.»;

Программаның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2023 елда урнаштыруга планлаштырыла торган кору инфраструктурасы объектлары | | | |
| 1. | «Талони» торак комплексының ябык паркингы | Казан шәһәре, Гаврилов ур., 6001 нче объект | 30 |
| 2. | Татарстан Республикасы территориясендә кертелә торган компрессор станцияләрендә җиде кору инфраструктурасы объекты | урнаштыру факты буенча | - |
| 3. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 ел-ның 23 августындагы 2290-р номерлы боерыгы белән расланган электр автомобиль транспортын җитештерүне һәм | урнаштыру факты буенча | -». |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | алардан файдалануны үстерү буенча чаралар планы («юл картасы) нигезендә кертелә торган кору инфраструктурасының 20 объекты | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин